**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Чит ил федератив дәүләтләре субъектларында яисә чит ил дәүләтләренең административ-территориаль берәмлекләрендә, чит ил дәүләтләрендә Татарстан Республикасы вәкилләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» Указына үзгәреш кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Чит ил федератив дәүләтләре субъектларында яисә чит ил дәүләтләренең административ-территориаль берәмлекләрендә, чит ил дәүләтләрендә Татарстан Республикасы вәкилләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2006 елның 25 декабрендәге ПУ-583 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 28 гыйнварындагы ПУ-33 номерлы, 2009 елның 17 ноябрендәге ПУ-612 номерлы, 2013 елның 29 октябрендәге ПУ-1046 номерлы, 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы, 2018 елның 22 мартындагы ПУ-241 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 3 февралендәге 84 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), 2 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле позиция өстәп, үзгәреш кертергә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| « | Татарстан Республикасының Беларусь Республикасындагы сәүдә-икътисадый вәкиле | 2 750 | ». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 20 июненнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 27 декабрь
№ 1025